СОВЕТ ЗИРЕКЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 53,
с. Ерыклы, 423185

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Ленин урамы, 53,
Зирекле авылы, 423185

тел., факс: (8-4348) 38-6-76, zarek.nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2022 елның 29 августыннан № 24-81

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

- төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү һәм әлеге мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу тора.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдим кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге башкарма комитетына:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру буенча Яңа Чишмә муниципаль районының вәкаләтле органы белән килешү төзергә;

Зирекле авыл җирлеге Советының 2022 елга һәм 2023, 2024 еллар план чорына җирлек бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләү һәм карау өчен тәкъдим итү.

3. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны Яңа Чишмә муниципаль районы җирлеге бюджетыннан ел саен Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбенә тапшыру башкарыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре

порталы составында Яңа Чишмә муниципаль районының мәгълүмат сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы Җ.Г. Гайфетдинов